**ГЛАВА РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

07.07.2023 Балык Бистәсе штп. № 14рг

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен үзвакытында карау максатларында, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшләү тәртибен расларга.

2. Сишәмбе көнне 14.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппаратында шәхси мәсьәләләр буенча **гражданнарны кабул итү көне** дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы Аппаратында гражданнарны шәхсән кабул итүне гамәлгә ашыруга, шулай ук җавап-хатларга кул куюга – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгына, аның урынбасарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесенә һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесенә аларның компетенцияләренә ярашлы рәвештә вәкаләт бирергә.

4. Җаваплы итеп билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратына язма рәвештә почта элемтәсе аша, электрон документ әйләнешенең Ведомствоара системасында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-кабул итү бүлмәсе аша кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен үзвакытында теркәү өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппараты оештыру бүлегенең баш белгечен;

- гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү буенча эш алып баруны оештыру өчен – Татарстан Республикасы Слобода муниципаль район Советы Аппаратының оештыру бүлеге башлыгын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы, аның урынбасары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе тарафыннан гражданнарны шәхсән кабул итүне оештыру өчен һәм гражданнарны шәхсән мөрәҗәгать итү буенча теркәүне гамәлгә ашыру, шәхси кабул итү карточкаларын тутыру, шулай ук «кайнар линия»телефоны буенча кабул ителгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен ведомствоара электрон документ әйләнеше системасына кертү өчен – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппараты оештыру бүлегенең баш белгечен.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 10 мартындагы 04рг номерлы күрсәтмәсен (боерыгын) үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге күрсәтмәне (боерыкны) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Күрсәтмәнең (боерыкның) үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе Ф.М. Вафинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2023 елның 7 июлендәге
14пг номерлы күрсәтмәсе (боерыгы)
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшләү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе гражданнарының язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен (алга таба - мөрәҗәгатьләрне) кабул итү, исәпкә алу, теркәү, карау, аларны карауны һәм үтәүне тикшереп тору кагыйдәләрен билгели, мөрәҗәгатьләрдәге мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү тәртибен, мөрәҗәгатьләрнең сәбәпләрен һәм характерын ачыклауны, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппаратында гражданнарны шәхсән кабул итүне оештыруны тәгаенли (алга таба – Совет аппараты).

Тәртип нигезләмәләре «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - Федераль закон) һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә каралырга тиешле барлык мөрәҗәгатьләргә дә кагыла.

1.2. Гражданнарның язма мөрәҗәгатьләре тәкъдимнәр, гаризалар һәм шикаятьләр рәвешендә килә.

Гражданның язма рәвештә бәян ителгән мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать җибәрелә торган җирле үзидарә органының исеме (аталышы) һәм адресы яисә тиешле вазыйфаи затның (урындагы кешенең) фамилиясе, исеме, атасының исеме яки тиешле затның вазыйфасы, шулай ук тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын бәян итү, үз фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), җавап җибәрелергә тиешле почта адресы, хәбәрнамәне җибәрү өчен кире адрес, шәхси имзасы һәм датасы булырга тиеш.

Кирәк булган очракта граждан үз дәлилләрен раслап язма мөрәҗәгатькә документларны һәм материалларны яки аларның күчермәләрен терки.

Җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта) мәҗбүри рәвештә күрсәтә, җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә булырга тиеш. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә теркәргә хокуклы.

Гражданнар тәкъдимнәр, гаризалар, шикаятьләр белән Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, туган телләрендә яисә Россия Федерациясе

халыкларының үзләре белгән теләсә кайсы телендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Гражданнарның тәкъдимнәренә, гаризаларына, шикаятьләренә җаваплар мөрәҗәгать телендә бирелә. Мөрәҗәгать телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

1.3. Хәл итү (чишү) Совет аппараты яисә вазыйфаи зат компетенциясенә керми торган мәсьәләләрне үз эченә алган язма мөрәҗәгатьләр теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелә, Федераль законның 11 маддәсендәге 4 өлешендә күрсәтелгән очрактан гайре, мөрәҗәгатьне яңадан (кабаттан) адреслау турында мөрәҗәгать юллаган гражданга хәбәр итү юлы белән. Хәбәрнамә текстында Законның тиешле маддәсенә сылтама булырга тиеш. Хәбәрнамәнең икенче нөсхәсе эшкә (делога) беркетелә.

Миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу ихтималы фактлары турында мәгълүматны үз эченә алган язма мөрәҗәгать федераль башкарма хакимият органының эчке эшләр өлкәсендәге территориаль органына һәм Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) теркәлгән көннән алып биш көн эчендә җибәрелә мөрәҗәгать җибәргән гражданга мөрәҗәгатьнең яңа адреска юллануы турында хәбәр итеп, Федераль законның 11 маддәсенең 4 өлешендә күрсәтелгән очрактан гайре.

Язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү берничә дәүләт органы, җирле үзидарә органнары яисә вазыйфаи затлар компетенциясенә кергән очракта мөрәҗәгатьнең күчермәсе теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә тиешле дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә тиешле вазыйфаи затларга җибәрелә.

1.4. Карарга яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка шикаятьне юллау тыела.

Әгәр шушы тыюга бәйле рәвештә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка шикаятьне юллау мөмкин булмаса, шикаять гражданга, аның тиешле карарга яисә гамәленә (гамәл кылмавына) билгеләнгән тәртиптә судка шикаять бирү хокукы аңлатылып, кире кайтарыла.

1.5. Әгәр язма мөрәҗәгатьнең тексты укырлык (таныйрлык) булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул аларның компетенциясе нигезендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка карау өчен җибәрелми, бу хакта мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә мөрәҗәгать җибәргән гражданга, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укып булырлык булса, хәбәр ителә. Әлеге мөрәҗәгать эшкә (делога) теркәлә.

1.5.1. Язма мөрәҗәгатьнең тексты тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул аларның компетенциясе нигезендә карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җибәрелми, мөрәҗәгать теркәлгәннән соң җиде көн эчендә мөрәҗәгать җибәргән гражданга ул хакта хәбәр ителә.

1.6. Мөрәҗәгать җибәргән гражданның фамилиясе яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы булмаган язма мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Мондый мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы

(алга таба-район Башлыгы) карары белән тиңдәшле делога теркәлә. Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, башкарыла торган яисә кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы зат турында мәгълүмат булса, мөрәҗәгать тиешле компетенцияле дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

1.7. Гражданнар Совет аппаратына, Совет аппаратының вазыйфаи затларына үз вәкилләре аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.8. Суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә әлеге суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать җибәргән гражданга кире кайтарыла.

1.9. Әгәр кергән язма мөрәҗәгатьтә Совет аппараты вазыйфаи затының, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар яисә яман сүзләр булса, ул анда куелган сорауларның асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин. Бу очракта мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгатькә хокуктан явызларча файдалануның ярамавы турында хәбәр ителә.

1.10. Гражданның язма мөрәҗәгатендә элек җибәрелгән мөрәҗәгатьләргә бәйле рәвештә асылда күп тапкырлар язма җаваплар бирелгән сорау булса һәм мөрәҗәгатьтә яңа дәлилләр яисә хәлләр китерелмәсә, район Башлыгы әлеге мөрәҗәгатьнең һәм элек җибәрелгән мөрәҗәгатьләрнең Совет аппаратына яисә бер үк вазыйфаи затка берничә тапкыр җибәрелүе шарты белән чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсезлеге һәм граждан белән хат алышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр ителә.

1.10.1. Совет аппаратына яисә вазыйфаи затка җавап Федераль законның 10 маддәсендәге 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru урнаштырылган сорауны үз эченә алган язма мөрәҗәгать кергән очракта мөрәҗәгать җибәргән гражданга мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтның мөрәҗәгатьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган электрон адресы хәбәр ителә, бу чакта суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгать кире кайтарылмый.

1.11. Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап дәүләт сере яисә федераль закон белән саклана торган башка сер булып торган мәгълүматларны ачмыйча бирелә алмаган очракта мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга, күрсәтелгән мәгълүматларны фаш итүнең ярамаганлыгына бәйле рәвештә, анда куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәрнамә юллана.

1.12. Мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча җавап бирелмәү сәбәпләре соңыннан бетерелгән очракта, граждан кабат мөрәҗәгатьне җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җибәрергә хокуклы.

## 2. Гражданнарның язма мөрәҗәгатьләрен кабул итү, теркәү һәм исәпкә алу

2.1. Почта аша килү ихтимал булган шартлагыч, агулы һәм башка хәтәр әйберләр салынганны вакытында ачыклау һәм зарарсызландыру максатларында, посылкаларны тышкы яктан карау уздырыла. Җибәрелгән мондый әйберләр

ачыкланган яисә аларның булуында шик туган очракта почта җибәрүләре белән алга таба эш кичекмәстән туктатыла һәм куркынычсызлык органының тиешле бүлекчәсе белгечe чакырыла. Белгечне чакыру белән бер үк вакытта почта аша килгән әйберне мәҗбүри изоляцияләү белән куркынычсызлык чаралары күрелергә тиеш.

Террорчылык актлары һәм башка җинаятьләр кылу куркынычы булган язма мөрәҗәгатьләр алынганда оператив-эзләү чараларын һәм тикшерү гамәлләрен үткәргәндә файдаланылырга мөмкин булган эзләрне саклап калу өчен чаралар күрелә.

2.2. Язма мөрәҗәгатьләрне кабул иткәндә аларның адресының дөреслеге тикшерелә. Тиешле урынга җиткерелмәгән хатлар кичекмәстән почта элемтәсе предприятиесенә адресатка җибәрү өчен ачылмыйча кире кайтарыла.

Конвертларны ачканда аларда конвертка беркетелә торган хат һәм документлар булу-булмавы тикшерелә (ертылган документлар ябыштырыла), килгән документлар (паспорт, хәрби билет, хезмәт кенәгәсе, пенсия таныклыгы һ.б., шулай ук фотосурәтләр һәм хатка башка кушымталар) хат текстының алгы беркетмәсе астына скрепка белән беркетелә. Хатның кушымтасы яки тексты булмавы ачыкланган очракта, конвертка белешмә салына һәм бу хакта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

2.3. Барлык язма мөрәҗәгатьләр дә Совет аппаратына кергәннән соң өч көн эчендә теркәлә. Һәр мөрәҗәгатькә хәреф тамгалары белән тәртип буенча теркәлү номеры бирелә: ог/с. Һәр яңа календарь елында яңа кергән мөрәҗәгатьләргә нумерация беренче номердан башлана. Теркәлгәннән соң кергән барлык мөрәҗәгатьләрне андагы мәгълүматка карата алдан карау оештырыла. Әлеге процедураның максаты – Совет аппаратына гражданнардан кергән коррупция фактлары буенча мөрәҗәгатьләрнең санын билгеләү.

Кергән барлык корреспонденциядән коррупциячел хокук бозулар турында мәгълүмат тупланган мөрәҗәгатьләр ачыклана (муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләре (гамәл кылмавы) акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт яисә мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр, үзе өчен яисә өченче затлар өчен мөлкәти хокуклар алу максатларында вазыйфаи хәлдән гражданнарның законлы мәнфәгатьләренә карамастан законсыз файдалануга бәйле булуын күрсәтүче фактлардагы белешмәләр).

Әлеге процедура шушы Тәртипнең 3 бүлегендә каралган аерым тәртиптә карала торган мөрәҗәгатьләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

2.4. Язма мөрәҗәгатьләргә резолюцияләр озата баручы (бергә җибәрелә торган) хатның өске сул почмагында яисә мөрәҗәгать итүче хатының беренче битендә рәсмиләштерелә. Резолюциядә вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, резолюция тексты (кирәк булганда - конкрет күрсәтмәләр һәм үтәү датасы белән), имза һәм дата булырга тиеш. Электрон документ әйләнеше ведомствоара системасында резолюцияләр система таләпләре нигезендә төзелә.

2.5. Әгәр җитәкче резолюциясендә берничә башкаручы күрсәтелгән булса, хатта куелган барлык сорауларны үтәү өчен хатта беренче булып күрсәтелгән башкаручы җаваплы була.

2.6. Совет аппаратына кәгазьдә кергән язма мөрәҗәгатьләр мәҗбүри рәвештә сканерлана һәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында йөкләнә.

2.7. Гражданның шикаятендә күрсәтелгән күрсәткечләр ахыргы карар чыгару өчен җитәрлек булмаса, гамәлләренә шикаять белдерелә торган учреждениедән яисә заттан карар кабул итүнең нигезлелеге турында бәяләмә белән тикшерү материаллары соратып алына. Кирәк булганда, район Башлыгы күрсәтмәсе буенча шикаятьне тикшерү өчен Совет аппараты хезмәткәрләре хезмәт урыны сәфәренә (командировкага) җибәрелә ала.

2.8. Әгәр барлык сораулар каралса, алар буенча тиешле чаралар күрелсә һәм гамәлдәге законнарга туры килә торган тулы җаваплар бирелсә, гражданнарның хатлары хәл ителгән (чишелгән) дип санала.

2.9. Мөрәҗәгатькә әзерләнгән җавап проекты эчке сул почмакта башкаручы тарафыннан виза ала һәм район Башлыгына, аның урынбасарына, Совет аппараты җитәкчесенә үз компетенцияләре нигезендә кул куюга тапшырыла.

2.10. Совет аппаратының вазыйфаи затлары:

а) мөрәҗәгатьне объектив, һәрьяклап һәм вакытында карауны тәэмин итәләр, кирәк булганда – мөрәҗәгать җибәргән граждан катнашында;

б) мөрәҗәгатьне карау өчен башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм башка вазыйфаи затлардан, судлардан, сорау алу органнарыннан һәм алдан тикшерү органнарыннан тыш, кирәкле документларны һәм материалларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, соратып алалар;

в) гражданның бозылган хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызуга яисә яклауга юнәлдерелгән чаралар күрәләр;

г) мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язма җаваплар бирәләр, моңа әлеге Тәртипнең 1.5, 1.5.1.,1.6., 1.8., 1.9., 1.10., 1.10.1., 1.11., 1.12 пунктларында күрсәтелгән очраклар керми.

д) гражданга аның мөрәҗәгатен карау өчен башка дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә үз компетенцияләре нигезендә башка вазыйфаи затка җибәрү турында хәбәр итәләр.

2.11. Мөрәҗәгатьне караганда мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы мәгълүматларны аның ризалыгыннан башка тарату рөхсәт ителми.

Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгать җибәрү мөрәҗәгатьтәге мәгълүматларнгы тарату булып тормый.

2.12. Совет аппаратына яисә вазыйфаи затка үз компетенцияләре нигезендә кергән гражданнарның язма мөрәҗәгатьләре, Федераль законның 12 маддәсендәге 1.1 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, язма мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә карала.

2.13. Совет аппаратына кергән һәм Совет аппараты бүлекчәләренә башкару өчен тапшырылган мөрәҗәгатьләрне карау срогының башы булып аларны теркәү көне санала.

Мөрәҗәгатьләрне карау срогының ахыры булып мөрәҗәгать авторына җавап имзалау датасы санала.

2.14. Билгеләнгән тәртиптә каралган мөрәҗәгатьләр буенча карарлар чикләнгән таралыштагы хезмәт мәгълүматына кертелергә тиеш түгел.

Мөрәҗәгатьтә куелган сорауның асылы буенча җавап дәүләт яисә федераль закон белән саклана торган башка сер булып торган белешмәләрне ачмыйча бирелә алмаган очракта, мөрәҗәгатьне юллаган гражданга, күрсәтелгән

белешмәләрне ачу ярамаганлыктан, анда куелган сорауның асылы буенча җавап бирү мөмкин түгеллеге турында хәбәр ителә.

2.15. Язма мөрәҗәгатькә җавап район Башлыгы яки район Советы бланкында әзерләнә һәм район Башлыгы, аның урынбасары яки аппарат җитәкчесе тарафыннан үз компетенцияләре нигезендә имзалана. Җавап граждан тарафыннан күрсәтелгән адреска җибәрелә.

Мөрәҗәгать буенча гражданга җавап проекты имзага район Башлыгына, аның урынбасарына яисә Совет аппараты җитәкчесенә мөрәҗәгатьне карау срогы тәмамланырга 5 эш көне кала тапшырыла.

Ике һәм аннан күбрәк затның мөрәҗәгатенә җавап (күмәк мөрәҗәгать) мөрәҗәгатьтә җавап алучы яисә мөрәҗәгатьне имзалаган гражданнар коллективы вәкиле буларак күрсәтелгән затка җибәрелә. Әгәр күмәк мөрәҗәгатьтә җавап алучы билгеләнмәгән булса, җавап мөрәҗәгать итүчеләр (имза салучылар) исемлегендә үзенең яшәү урыны адресын күрсәткән беренче гражданга җибәрелә. Күмәк мөрәҗәгатькә җавап җибәрү турындагы үтенеч берничә мөрәҗәгать иткән (имза куйган) зат тарафыннан белдерелгән очракта, җавап күчермәсе аларның һәркайсына алар күрсәткән почта адреслары буенча җибәрелә.

Мөрәҗәгатькә җавап электрон документ рәвешендә Совет аппаратына яисә электрон документ рәвешендәге вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресына һәм язма рәвештә Совет аппаратына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресына җибәрелә. Моннан тыш, Совет аппаратына яисә вазыйфаи затка тәкъдиме, гаризасы яисә шикаяте булган, затларның билгесез даирәсе мәнфәгатьләренә кагыла торган мөрәҗәгатькә, аерым алганда, затларның билгесез даирәсенә карата чыгарылган суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, Федераль законның 6 маддәсендәге 2 өлеше һәм әлеге Тәртипнең 2.11 пункты таләпләрен үтәгән килеш, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырылырга мөмкин: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru.

Гражданның мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон адресы буенча мөрәҗәгатенә җавапларны җибәрү җавап әзерләгән вазыйфаи затның (башкаручының) почта тартмасыннан гамәлгә ашырыла. Экранның скриншоты формасында раслау Совет аппаратының оештыру бүлегенә җибәрелә.

Мөрәҗәгатькә җавап имзаланганнан соң җаваплы башкаручы аны хат адресатын тутырып конвертка тутыра һәм почта җибәрүләре реестры аша җибәрү өчен Совет аппаратының оештыру бүлегенең баш белгеченә тапшыра.

## 3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауны тикшереп тору

3.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен тәэмин итүне тикшереп тору Совет аппаратының оештыру бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 4. Гражданнар мөрәҗәгатьләре турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык.

4.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүне оештыру өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләнә.

4.2. Гражданнарның язма мөрәҗәгатьләрен теркәү, шулай ук гражданнарны шәхсән кабул итү карточкаларын теркәү өчен Совет аппаратының оештыру бүлегенең баш белгече җаваплы.

4.3 Гражданнар мөрәҗәгатенә җавапны вакытында әзерләмәгән һәм аны тиешле сыйфатта рәсмиләштермәгән өчен, шулай ук җавапларның эчтәлеге, ачыклыгы һәм төгәл бәян итү өчен, норматив актларга сылтамаларның дөреслеге өчен җаваплылык җаваплы башкаручыга йөкләнә.

4.4Хаталар өчен җавапны электрон почта тартмасыннан җибәргәндә адресны күрсәтүдә, шулай ук почта аша җибәргәндә җавапны әзерләгән җаваплы башкаручы җаваплы була.

## 5. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе

5.1. Коррупцион хокук бозулар булуы ихтималлыгы ачыкланган мөрәҗәгатьне алдан карау процедурасын үткәргәннән соң, мөрәҗәгать кичекмәстән район Башлыгына тапшырыла.

Район башлыгы резолюция сала һәм башкаручыларны билгели. Мөрәҗәгатьне карау аерым контрольгә куела.

5.2 Мөрәҗәгать карарлары яисә гамәлләре (гамәл кылмавы) мөрәҗәгать предметы булган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җибәрелми.

5.3. Мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, кылына торган яисә кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яисә кылган зат турында белешмәләр булган очракларда мөрәҗәгать аның компетенциясе нигезендә дәүләт органына теркәлә һәм җибәрелә.

5.4.Мөрәҗәгатьтә муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәткә бәйле бурычларны, чикләүләрне һәм тыюларны, шулай ук хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәмәве, муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы булуы, мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килүе, муниципаль хезмәткәрнең башка коррупцион хокук бозулар кылу ихтималы турында мәгълүматлар булган очракта Район башлыгы мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактларга карата коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе вазыйфаи затының (коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазыйфаи затларның) доклад язмасы нигезендә тикшерү үткәрүнең максатка ярашлылыгы турында карар кабул итә. Әлеге тикшерү хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең үтәлешен (муниципаль хезмәткәрләрнең «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда,

башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын (низагын) булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәвен, аларның бурычларын үтәвен) тикшерү булып тора һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан республиканың норматив хокукый актлары нигезендә үткәрелә.

5.5.Мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар оператив-эзләү чараларын уздыру юлы белән тикшерүгә мохтаҗ булган очракта, мөрәҗәгатьне карау барышында оператив-эзләү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт органнарына гарызнамә җибәрелә.

5.6Күрсәтелгән тикшерү үткәргәндә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәвен раслый торган фактлар билгеләнгән очракта, Район башлыгы тикшерү материалларын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын (каршылыгын, низагын) җайга салу комиссиясенә (алга таба-Комиссия) бирү турында карар кабул итә. Күрсәтелгән мәсьәләне карау турында карар кабул ителгәндә комиссия утырышында утырышның датасы, вакыты һәм урыны билгеләнә, шулай ук норматив хокукый актлар нигезендә Комиссия утырышын әзерләү эше оештырыла.

5.7Мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча мөрәҗәгать итүчегә җавапта үткәрелгән чаралар һәм тикшерүләр нәтиҗәләре турында, комиссия карарлары турында (булган очракта), шулай ук кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән муниципаль хезмәткәргә карата җаваплылык чаралары куллану турында яки тикшерү үткәрү өчен нигезләр булмау турында һәм коррупция фактларын расламау турында мәгълүмат бирергә тиеш.

5.8Гражданнарның коррупция юнәлешендәге фактлар буенча Совет аппаратына кергән мөрәҗәгате әлеге Тәртиптәгечә каралырга тиеш.

5.9 Мөрәҗәгать гражданга мөрәҗәгатьтә куелган барлык сорауларга җавап җибәрелгәннән соң контрольдән алына.

## 6. Гражданнарның «кайнар линия» телефоны буенча кабул ителгән мөрәҗәгатьләрен карау

6.1. Әлеге бүлек Совет аппаратындагы «кайнар линия» телефонының (алга таба – «кайнар линия») эшләү, кергән мөрәҗәгатьләрне кабул итү, теркәү һәм исәпкә алу тәртибен билгели.

6.2. «Кайнар линия» телефоны буенча мөрәҗәгатьләр һәр пәнҗешәмбедә (бәйрәм көннәреннән тыш) 8.00 дән 12.00 гә кадәр һәм 13.30 дан 16.30 га кадәр (884361) 22-113 номеры буенча кабул ителә.

6.3. «Кайнар линия» телефонының эшләве һәм эш режимы турындагы мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чаралары аша Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм Башкарма комитет бинасы вестибюлендәге мәгълүмат

стендларында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерелә: ТР, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык бистәсе штп., Ленин ур., 48 йорт.

6.4. Совет аппаратына «кайнар линия» телефоны буенча гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр мәҗбүри теркәлергә тиеш.

6.5. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен «кайнар линия» телефоны буенча кабул итү һәм теркәү әлеге Тәртип нигезендә Совет аппаратының оештыру бүлегенең баш белгече (алга таба – баш белгеч) тарафыннан башкарыла.

6.6. Гражданнарның «кайнар линия» телефонына мөрәҗәгатьләрен исәпкә алу өчен исәпкә алу журналы кулланыла, анда гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү адресы, аның соравының кыскача эчтәлеге һәм карау нәтиҗәсе күрсәтелә.

6.7. Гражданнарның суд карарларына, конкрет фактлар булмаган мәгълүматка, шулай ук кимсетүле характердагы мәгълүматка карата шикаять белдерелгән телефон мөрәҗәгатьләре теркәлми.

6.8. Гражданнарга мәгълүмат бирү алар тарафыннан шәхси мәгълүматлар (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), телефон номеры, кирәк булганда җавап җибәрелергә тиешле почта адресы) тапшырылганнан һәм мөрәҗәгатьнең асылы бәян ителгәннән соң гамәлгә ашырыла.

6.9. Кабул ителгән телефон хәбәре баш белгеч тарафыннан язма рәвештә «кайнар линия» буенча дата, вакыт 1 нче кушымта нигезендә алынды» дигән тамга белән рәсмиләштерелә һәм район Башлыгына карауга җибәрелә. Аның белән алга таба эш гражданнарның язма мөрәҗәгатьләрен карау өчен каралган тәртиптә башкарыла. Һәр квартал, яртыеллык, ел йомгаклары буенча, хисаптан соң килүче айның 15 числосына кадәр Совет аппаратының оештыру бүлеге баш белгече район Башлыгына гражданнардан килгән телефон мөрәҗәгатьләренең саны, характеры һәм сәбәбе, аларны карау буенча күрелгән чаралар турында хисап тапшыра.

6.10. Исәпкә алу журналлары һәм гражданнарның телефон мөрәҗәгатьләренә бәйле материаллар эш башкару Кагыйдәләре нигезендә Совет аппаратында 3 ел саклана, аннары билгеләнгән тәртиптә юкка чыгарыла.

## 7. Гражданнарны шәхсән кабул итүне оештыру

7.1. Гражданнарны район Башлыгы, аның урынбасары, Совет аппараты җитәкчесе, Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе шәхсән кабул итә.

7.2. Совет Аппаратында гражданнарны кабул итү өчен махсус бүлмә - кабул итү бүлмәсе бирелә.

Гражданнарны кабул итү урыны, кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр, гражданнарны кабул итүгә әзерлек өчен җаваплы вазыйфаи затларның контакт телефоннары турындагы мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чаралары аша гражданнарга җиткерелә һәм Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырыла: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. Күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук Башкарма комитет бинасы вестибюлендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла, адресы: ТР, Балык Бистәсе муниципаль районы,

Балык бистәсе штп., Ленин ур., 48 йорт. Кабул итү үткәрелә торган бинада гражданнарны кабул итүгә турыдан-туры катнашы булмаган затларга булу тыела.

Гражданнар район Башлыгының, аның урынбасарының яисә район Советы Аппаратының башка вазыйфаи затларының эш кабинетларында кабул ителә. Кирәк булганда, очрашулар гражданнарның яшәү яки эшләү урыны буенча оештырыла.

7.3Район Башлыгының кабул итү бүлмәсендә телдән мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеге баш белгеч тарафыннан гражданның шәхсән кабул итү карточкасына (2 нче кушымта) кертелә, анда гражданны кабул итү датасы, аның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), аның яшәү урыны адресы, кабул итүне алып баручы вазыйфаи (вәкаләтле) затның фамилиясе, телдән мөрәҗәгатьнең эчтәлеге һәм аның буенча күрелгән чаралар турында белешмәләр булырга тиеш. Күрсәтелгән реквизитларга башка кирәкле мәгълүматлар өстәлергә мөмкин.

7.4Гражданнарны шәхсән кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә беренче чиратта шәхсән кабул итү хокукына ия:

1) I, II төркем инвалидлар һәм (яисә) аларның законлы вәкилләре (ата-аналарның, уллыкка алучыларның берсе, опекун яисә попечитель);

2) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары;

3) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

4) өч яшькә кадәрге балалар белән кабул итүгә килгән гражданнар.

7.5Шәхсән кабул иткәндә граждан аның шәхесен таныклаучы документны күрсәтә. Граждан мондый документны күрсәтүдән баш тарткан очракта, аның мөрәҗәгате аноним буларак карала. Шәхсән кабул иткәндә 5.4 нче пунктның 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар. әлеге Тәртиптә, беренче чиратта шәхси кабул итү хокукын раслый торган документ күрсәтәләр. Беренче чиратта шәхси кабул ителү хокукына бер ук вакытта берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхсән кабул ителүгә килү тәртибендә гамәлгә ашырыла.

7.6 Кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи (яисә вәкаләтле) зат гражданны игътибар белән тыңларга һәм аның мөрәҗәгатенең асылын җентекләп тикшерергә тиеш. Әгәр телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар һәм хәлләр ачык күренеп торса һәм өстәмә тикшерү таләп ителмәсә, гражданның ризалыгы белән мөрәҗәгатькә җавап шәхсән кабул итү барышында телдән бирелергә мөмкин, бу хакта гражданның шәхси кабул итү карточкасына язып куела һәм гражданның имзасы белән таныклана. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язма җавап бирелә.

Шәхсән кабул итү барышында кабул ителгән язма мөрәҗәгать Федераль законда һәм әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртиптә теркәлергә һәм каралырга тиеш.

Мөрәҗәгатьтә хәл ителеше Совет аппараты яисә вазыйфаи зат компетенциясенә керми торган мәсьәләләр булган очракта, гражданга кая һәм нинди тәртиптә мөрәҗәгать итәргә кирәклеге аңлатыла.

Шәхсән кабул итү барышында гражданга мөрәҗәгатьне алга таба караудан баш тартылырга мөмкин, әгәр аңа мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча элегрәк җавап бирелгән булса.

7.7Совет аппаратының вазыйфаи затлары гражданнарны шәхсән кабул итүгә бәйле мәсьәләләр буенча җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре аларга ярдәм күрсәтергә һәм ярдәм итәргә тиешле башка җирле үзидарә органнарына, предприятиеләргә, учреждениеләргә яисә оешмаларга мөрәҗәгать итәргә хокуклы: кирәкле белешмә һәм мәгълүмати материаллар тапшырырга (норматив хокукый актлар нигезендә таратылырга тиеш булмаган белешмәләрдән тыш), квалификацияле консультацияләр, элемтә белән тәэмин итәргә, хезмәткәрләрне кабул итүне гамәлгә ашыру өчен җибәрергә һ. б.

7.8.Граждан кабул итү бүлмәсендә әйләнә-тирәдәгеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч тудыра торган гамәлләр кылган очракта, кабул итүне алып баручы вазыйфаи (яисә вәкаләтле) зат Россия Федерациясе законнары нигезендә кирәкле чаралар күрә. Кирәк булганда эчке эшләр һәм ашыгыч медицина ярдәме органнары хезмәткәрләре чакырыла.

## 8. Мөрәҗәгатьләр белән эшләүнең торышын тикшерү һәм аларны карауны тикшереп тору. Мөрәҗәгатьләрдәге мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү

8.1Совет аппаратының вазыйфаи затлары мөрәҗәгатьләрне карау тәртибенең үтәлешен үз компетенциясе чикләрендә тикшереп торалар, кергән мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеген анализлыйлар, гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу сәбәпләрен вакытында ачыклау һәм бетерү буенча чаралар күрәләр.

8.2 Яртыеллыкта кимендә бер тапкыр мөрәҗәгатьләрне карау һәм алар буенча карар кабул итү эшенә эчке тикшерү үткәрелә, моның өчен район Башлыгы күрсәтмәсе белән комиссия билгеләнә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзелә, мөрәҗәгатьләрне карау тәртибен бозулар ачыкланган очракта, анда аларны бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту буенча тәкъдимнәр булырга тиеш.

8.3 Совет аппаратында башкару сроклары буенча барлык язма мөрәҗәгатьләр, шулай ук карау таләп ителә торган нәтиҗәләр турында гражданнарны шәхси кабул итүгә мөрәҗәгатьләр булырга яисә тиешле орган яисә вазыйфаи зат таләбе буенча мәгълүмат бирергә тиеш.

8.4 Контроль буенча турыдан-туры эш контроль буенча вәкаләтләр бирелгән Совет аппараты вазыйфаи затларына йөкләнә.

Мондый контрольне гамәлгә ашыручы затлар хокуклы:

а) мөрәҗәгатьләрне карау барышы турында башкаручылардан һәм аларның турыдан-туры җитәкчеләреннән кирәкле белешмәләр (мәгълүматлар) соратып алырга;

б) мөрәҗәгатьләрне карау торышын чагылдыра торган материаллар белән билгеләнгән тәртиптә танышырга;

в) мөрәҗәгатьләрне карауны тикшереп тору барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча тиешле вазыйфаи затларга тәкъдимнәр кертергә.

8.5.Мөрәҗәгатьләрне карауны тикшереп торуның барышы турында айга бер тапкырдан да сирәгрәк түгел, район Башлыгына хәбәр ителә.

8.6.Гражданнар мөрәҗәгатьләре керүгә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында һәр ярты ел саен гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр гомумиләштерелә һәм анализ ясала. Күрсәтелгән анализда кергән, адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхсән кабул ителгән гражданнарның саны турында, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы хакында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат (булган очракта) булырга тиеш.

8.7Мөрәҗәгатьләр белән эшләү торышы (гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ) шулай ук район Башлыгы эшчәнлеге турында еллык хисапларда чагыла һәм квартал саен мәҗбүри рәвештә Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырыла: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru кушымта итеп бирелә торган рәвешләр буенча (кушымта №3, 4).

8.8Аналитик эш Совет аппаратының барлык бүлекчәләре белән тыгыз хезмәттәшлектә алып барыла. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен караучы белгечләр тематик язулар, башка аналитик материаллар язу өчен үзләренә беркетелгән өлкә буенча даими рәвештә материаллар сайлап алалар һәм туплыйлар (мөрәҗәгатьләрнең, аларга җавапларның күчермәләрен алалар), аналитик материаллар төзү өчен кирәкле мәгълүматны вакытында әзерлиләр.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратында Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшләү тәртибенә кушымта №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы

______________________

ГРАЖДАННЫҢ «КАЙНАР ЛИНИЯ» ТЕЛЕФОНЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ

«Кайнар линия» буенча алынды: ___ ________,20____ел ___ сәг. __ мин

Гражданның «кайнар линия»телефонына кергән мөрәҗәгате турында хәбәр итәм.

Фамилиясе_____________________________________________

Исеме ______________________________________________

Атасының исеме (булган сурәттә) ______________________________

Телефон номеры________________________________________

Почта адресы___________________________________________

Мөрәҗәгатьнең эчтәлеге____________________________________

_______________________________________________________

_______________________________________________________

_______________________________________________________

_______________________________________________________

_______________________________________________________

_______________________________________________________

_______________________________________________________

_______________________________________________________

_________________________

Җаваплы хезмәткәр_________________ (_________________)
(имза, дата) Имзаның расшифровкасы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратында Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшләү тәртибенә кушымта №2

**Балык Бистәсе муниципаль районы**
**Адрес: Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48йорт**

ГРАЖДАННАРНЫ ШӘХСӘН КАБУЛ ИТҮ КАРТОЧКАСЫ

№______ Кабул итү датасы: «    » __________, 2019 ел.

Фамилиясе ________________________________________________

Исеме ________________________________________________

Атасының исеме ________________________________________________

________________________________________________

Эш урыны, вазыйфасы________________________________________________

________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең адресы________________________________________________

________________________________________________

Контакт өчен телефон ________________________________________________

Мөрәҗәгать итүнең эчтәлеге________________________________________________

________________________________________________

________________________________________________

________________________________________________

Кабул итүне алып баручы җитәкченең фамилиясе:

Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре ________________________________________________

________________________________________________

________________________________________________

________________________________________________

________________________________________________

Үтәлеше турында билге

________________________________________________

________________________________________________

________________________________________________

________________________________________________

Контрольдән алынды________________________________________________

________________________________________________

______Дата ________________ Имза

________________________________________________

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратында Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшләү тәртибенә кушымта №3

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында
**СТАТИСТИК МӘГЪЛҮМАТЛАР**

| Мәгълүматларның аталышы | Цифрлы мәгълүматлар | |
|---|---|---|
| | ______ ел | _____ ел |
| Кергән барлык мөрәҗәгатьләр (хат, шәхсән кабул итү, электрон мөрәҗәгатьләр) | | |
| шул исәптән электрон мөрәҗәгатьләр (Интернет, электрон почта) | | |
| шул исәптән шәхсән кабул итүдә кабул ителде: | | |
| район Башлыгы тарафыннан | | |
| аның урынбасары т.-н | | |
| Совет аппараты җитәкчесе т.-н | | |
| коррупциягә каршы тору буенча район Башлыгы ярдәмчесе тарафыннан | | |
| Контрольгә алынды | | |
| Уңай хәл ителде | | |
| Урынга барып тикшерелде | | |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратында Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшләү тәртибенә кушымта №4

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүнең торышы турында МӘГЪЛҮМАТЛАР

| Адресат-мөрәҗәгатьләрне алучы | Мөрәҗәгатьләр саны | | | Карауның нәтиҗәләре | | | | Түбәндәге мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләр керде | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | Язма рәвештә | Телдән | аңлатылды | канәгатьләндерелде | Кире кагылды | Каралу стадиясендә | Сәнәгать | төзелеш | Агросәнәгать комплексы | транспорт | элемтә | Финанслар һәм банклар эшчәнлеге | Мәгариф, фән һәм мәдәният | Сәламәтлекне саклау | хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары эше | Эчке эшләр органнары эше | судлар, прокуратура, юстиция органнары эше | сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү | Коммуналь хуҗалык | Соц. яклау, соц. тәэминат | торак | дин | Хезмәт хакы түләү | Хезмәт һәм мәшгульлек | төрлеләр | БАРЫСЫ |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Вазыйфаның аталышы (исеме)

__________ (имза) ____________________ (имзаның расшифровкасы)